Галиуллина, М. Кылыч кадерлерәкме, әллә алкамы? / М. Галиуллина // Мәдәни җомга. – 2025. – №17 (30 апрель).

# Кылыч кадерлерәкме, әллә алкамы?

*А.Гыйләҗев исемендәге Чаллы Татар дәүләт драма театрында Айгөл Әхмәтгалиеваның Нәфикъ Яһудинның Оренбургтагы татар казаклары турындагы әсәренә нигезләнгән пьесасы буенча «Алтын алка» спектакле куелды. Татар сәхнәсендә яңа һәм аз өйрәнелгән тема күтәрелүе үзе вакыйга булса, сәхнәләребезне мәхәббәт, гыйшык-мыйшык турында җиңел рухлы әсәрләр баскан заманда татар яугирләрен зурлау әлеге вакыйганың әһәмиятен тагын да арттыра.*



Н.Яһудинның «Атлы казаклар» әсәре турында язучы Мирсәй Әмир узган гасырның җитмешенче еллары уртасында «Казан утлары» журналында (1975 ел, 5 нче сан) болай дип язган: «Сугыш алды елларында Казан педагогика институтын тәмамлап чыгып, Арча ягында укытып йөрүче Нәфикъ Яһудинны мин язучылар сафына ышанычлы адымнар белән килүче, әдәбиятыбызны яңа образлар белән баетырга тиешле өметле каләм иясе дип белә идем. Миңа аның төгәлләнеп бетмәгән бер романы белән танышырга туры килде. Роман Оренбург ягында яшәүче татар казаклары тормышын гәүдәләндерә иде. Гражданнар сугышы чорына багышланган бу әсәр мине әдәбиятыбызга яңалык алып килүе белән генә түгел, теле, стиле ягыннан да үзенчәлекле булуы белән бик нык кызыксындырган иде. Аны әдәби яктан тиешле дәрәҗәгә җиткерү өчен, авторга үз киңәшләремне әйттем. Ул аларны хуп күрде һәм әсәрен камилләштерү юнәлешендә бик ныклап ниләргә кереште. Ләкин тәмамларга өлгермәде, сугыш башланды...»

## ОРЕНБУРГНЫҢ ТАТАР КАЗАКЛАРЫ

Казак – төрки сүз. Ирек сөючән, маҗаралар эзләүче кешеләрне казак дип атаганнар. Оренбургта казаклар хәрәкәтенә 1736 елда нигез салына дип исәпли галимнәр. Язучы Вахит Имамов үзенең «Татар яугирләре» китабында Пугачев явының башлануын тасвирлаганда татарларның Җаек буена ничек килеп урнашулары һәм бередәге казакларда ни өчен тиз арада абруй казанулары турында язып үткән. «Беренче татарлар Җаек буйларына патша хөкүмәтенең аяусыз талауларына түзә алмыйча XVI гасырда ук килеп урнашкан. XVIII гасырда Казан губернасында татарларны изү аеруча көчәйгәч һәм бигрәк тә көчләп чукындыруга түзә алмыйча, Кама аръягына, Урал тавы, Агыйдел һәм Җаек буена качканнар. 1735 елда Җаек янында Оренбург каласы нигезләнгәч, татарлар бередә күмәк рәвештә күчеп утыра башлый», - дип яза В.Имамов. Аннары язучы мәгълүматларыннан Оренбург далаларына күчеп килгәч татарларның игенчелек, һөнәрчелек белән көн күргәнен, күбесе казак гаскәрләре сафларына басып, Россиянең көнчыгыш чикләрен саклауда кашашканнарын укып беләбез. «Казах Җүзләре чигендә төзелгән Красногорск, Верхне-Озерск, Борск кирмәннәренең гарнизоннары нигездә татар казакларыннан тора. 1774 елгы документларда Нижне-Озерск кирмәнендә Муса Мөслимов һәм Тимер Ямбулатов шикелле татар казакларының хөрмәт ителүе телгә алына. Самара сызыгындагы Мачын бистәсе татарларының һәммәсе казак хезмәтен башкара. Каргалы авылында, Ильинская, Сакмар кирмәннәрендә, Оренбург каласы белән Җаек шәһәрчегенең үзендә дә казак-татарлар **аз** булмый», - дип татар казакларының сан буенча күп булуын да әйтеп уза В.Имамов. Аңлашылганча, Җаек казаклары электән үк нинди дә булса өстенлекләрдән файдалана. Хөкүмәт аларга даими рәвештә хезмәт хакы (елына 12 сум чамасы) түли, болынлыклар бүләк итә, елгаларда балыкны бушлай тоту хокукын бирә, дигән сүзләрен китерә. «Шуңадыр, күрәсең, казакларның саны һаман арта», - дигән фикергә килә язучы. Аннары әдип «пугачевчы» галим А.Белыйның, 1770 еллар башында Җаек буендагы татар казакларының саны 2200 гә җитә, дигән сүзләрен китерә, Пугачев фетнәсендә дә татар казаклары бик актив катнашканын яза. Гарнизоны һәм халкы тулысынча диярлек татарлардан торган Кызылтау (Красногорск) кирмәненең фетнәчеләр ягына күчкәнен дәукып беләбез. Язучы бер кызыклы факт китергән: «Җаек буендагы башбаштаклыктан файдаланып, крепостька казах ханының сәрбазлары бәреп кереп, казакларның 233 баш атын, 636 сыерын талап алып китә. Әхмәт Габдуллов, Сибәй Колымбәтов, Күкләш Бикшсв, Ишкуәт Тимәкәев, Рәфыйк Бикеев кебек казакларның һәркайсы 10-15 аттан, 10-36 сыердан коры кала. Аяныч вакыйга булса да, саннар Россия чигенә качып гомер иткән татар казакларының иркен, мул тормыш белән белән яшәүләре хакында сөйли». Озак та үтми, Красногорскидагы Екатерина II гә хыянәт иткән казакларны патша солдатлары талап, тагын 2500 сумлык байлыктан мәхрүм итә. «Гарнизонга баш итеп куелган татар есаулы Гомәр Ермаковның байлыгы өчен генә түгел, ул төзегән документ белән ике гасырдан соң танышкан вакытта да милләтебез вәкилләренең укымышлылыгы, зирәклеге, пөхтәлеге өчен тирән хөрмәт белән искә алырга туры килә», - дип язган әдип. Шул ук вакытта кирмәндәге рус казакларының берешәр-икешәр ат, күп булса җиде баш сыер белән генә яшәп ятуларын белү язучыны гаҗәпләнергә һәм уйланырга мәҗбүр иткән. «Шартлар бер үк булгач, рус казаклары нигә болай ярлы яшәгән соң», - дип язган ул («Татар яугирләре», 23-35 битләр)...

Хәлим Абдуллин үзенең «Татары в Отечественной войне 1812 года и заграничных походах русской армии 1813-1814 годов» китабында Оренбург татарларының бу кампанияләрдә актив катнашканын язган. Бу чорда сугышларда үзләрен танытткан Мөхәммәтшәриф Ягафаров, Исхак Бәхтияров, Исхак Ибраһимов, Абдулхалик Абдулвахитов һәм, атаклы Дәүләтьяровлар нәселеннән булып, 3 нче Оренбург казак полкы составында Парижны алуда катнашкан Сәйфулла Гобәйдуллин, Абдулла Ибраһимов, Исхак Исмәгыйлев исемнәре китерелгән. Тарихчы Оренбург казаклары арасында ногайбәкләр төркеменең булуы турында да искәрткән. Бу төркемнән тарихчылар Яков Серебряков исемле казакны аерып чыгара. «Йортын, мал-мөлкәтен сатып, шуның акчасына 53 кешегә хәрби кием, корал алып, яуга әзерләгәне өчен император Александр I Серебряковны бүләкләгән», - диелә китапта. Яковка ул вакытта нибары 29 яшь була (17-36 битләр)...

## СПЕКТАКЕЛЬНЕҢ КУЕЛУ ТАРИХЫ

Күргәнебезчә, Оренбургта татар казаклары сан ягыннан шактый була һәм үз-үзләрен аямыйча сугышларда катнаша. Император яклы сугышалармы, әллә Пугачев фетнәсенә кушылалармы - анысы инде бүтән мәсьәлә...


Чаллыда исә Н.Яһудинның «Атлы казаклар» романына нигезләнеп иҗат ителгән спектакльнең режиссеры - Олег Кинҗәголов. Н.Яһудин Оренбург өлкәсендәге Яңа Чиркәсс авылында туган, яшьли ятим калып, өч ел Каргалы балалар йортында тәрбияләнгәннән соң, Оренбург педагогика

техникумы, аннан ары Казанда техникум тәмамлагач, Әтнә районындагы Олы Мәңгәр авылы мәктәбендә директор булып эшләгән. Бөек Ватан сугышында катнашып, Берлинга кадәр барып җиткән. Аннан әйләнеп кайткач, Башкортстанга күчеп, соңгы көннәренә кадәр шунда гомер кичергән. «Атлы казаклар» романын сугышка кадәр иҗат итсә дә, китап итеп бастырырга өлгерми кала, әсәр 2017 елда гына «Казан утлары»нда басылып чыга. Матбугатка аны язучының улы - үзе дә журналист, язучы Марс Яһудин әзерли. Язучы А.Әхмәтгалиева, моңа кадәр татар сәхнәләрендә күренмәгән татар казаклары темасына кызыгып, шушы роман нигезендә пьеса иҗат итә. Дөресрәге, әсәрнең беренче өлеше буенча яза ул драма әсәрен, чөнки ни кызганыч, өч өлеш буларак уйланылган роман тәмамланмый кала. Спектакль Татарстан Театр әһелләре берлеге грантына куелган. «Темасы кызык тоелса да, Җаек буендагы татар казаклары тормышы аз өйрәнелгән, шуңа күрә Оренбург архивларында, язучының туган авылы Чиркәсстә, китапханә, музейларда шактый эзләнергә туры килде», - дип сөйләде пьеса авторы А.Әхмәтгалиева. Әсәр совет заманында язылган. Ул елларда исә илдәге идеология бай катламны әзәрлекли, ярлыларны күтәрә. Әмма роман язылганнан соң күп еллар үтте, заманалар үзгәрде. Шуңа күрә әсәрне ничек бар, шулай сәхнәгә куярга ярамый иде. «Без әсәрне бераз үзгәрттек, - диде А.Әхмәтгалиева. - Әйтик, авылбае Муллагали авызыннан, авылда мәчет, мәдрәсә тотам, ярлы-ябагага эш бирәм, барыбер кешеләр канәгать түгел, дигән сүзләр әйттердек». Театрда премьера март ахырында була. Апрель ахырында исә спектакльне безгә дә барып карау бәхете эләкте. Бу көнне «Алтын алка»ны карарга язучы Н.Яһудинның уллары - Чаллыда яшәүче Марс ага хатыны Резидә ханым һәм Башкортстанның Күгәрчен районыннан Айрат абый хәләл җефете Гөлнур ханым белән килгән иде.

### ТАТАР КАЗАКЛАРЫ НИК РУСЧА ҖЫРЛЫЙ?

Спектакльдә вакыйгалар XX гасыр башында революция алдыннан бара. Авылда дус-тату булып ике гаилә - Хисамый белән Мәгузә (Равил Галиев һәм Флүзә Касаева) һәм Җәләй белән Мершидә (Рафил Сәгъдуллин һәм Алсу Хәбетдинова) гомер кичерә. Уллары Миңлебай (Илназ Гаффанов) һәм кызлары Мәрьямне (Алинә Мөхлисова) кечкенәдән ярәштереп куйганнар. Миңлебай авыл бае Муллагалигә (Рафик Каюмов) ялланып эшли. Байның улы Гарифҗан да (Руслан Әюпов) Мәрьямгә гашыйк. Миңлебай Мәрьямгә өйләнә, хәрби хезмәткә китеп, казаклар гаскәрендә зур абруй казана һәм алтын кылыч белән бүләкләнә. Әмма гөнаһ шомлыгына, авылда чакта аның Петлюк атлы украин кешесе (Марсель Мөсәвиров) коткысына бирелеп, патша хөкүмәтенә каршы листовка таратуы, революциягә чакыруы ачыклана.

Сәхнәгә куючы рәссам Ләйсән Хөсәенова киң дала күренеше төшереп арткы пәрдә иҗат иткән. Ул гобеленны хәтерләтә һәм



сәхнә күренешенә җылы өсти. Геройларның күлмәкләрендә чигелгән бизәкләр Оренбург татарларының борынгы һөнәрләрен бераз чамаларга мөмкинлек бирә. Спектакльдә авыл халкының печәнгә чыгуы, туй күренеше матур итеп сурәтләнгән. Туй күренешендә сәхнәгә ат арбасы тартып чыгулары гына да ни тора. Кияү пилмәне йоласы кызык. Кияү пилмәненең вак булуы, бер агач кашыкка биш пилмән сыюы, зурны ясасалар, «бака кадәр пилмән» дип гаеп итеп әйтәләр дип, галимнәребезнең Оренбургтагы милләттәшләребездән язып алып кайтканнарын укыган бар иде.

Алда әйтеп үтелгән ике гаиләнең бер-берсен хөрмәт итеп, дус булып яшәве милләтебезне матур яктан ача, күп кешелек җырлы-биюле күренешләр мәдәниятебезнең байлыгын күрсәтә, хәрби хезмәткә атлыгып, гаскәрдә бөтәннәрдән кыюлыгы, җитезлеге белән аерылып торган татар казакларына дан җырлана. Киң колач белән куелуын һәм сурәтләү чараларына бай матур телен әлеге спектакльнең уңай сыйфатлары дип билгеләп үтәргә мөмкин. Татар казакларының русча җырлавы гына күңелгә тия. Яугирләрнең үзебезчә җырлана торган җырлары, һичшиксез, булган. Әмма аларны табу өчен айлар түгел, еллар кирәк, мөгаен...

### АЛКАМЫ, КЫЛЫЧМЫ?

Кылыч уйнаткан курку белмәс яугирләр турында бу спектакльгә ник «Алтын алка» дип исем биргәннәр соң? Бу исемнең рус теленә «Золотая шашка» дип тәрҗемә ителүе өстәмә сораулар кудырды. Миңлебай Мәрьямгә алка бүләк итә. Алка ул мәхәббәт символы. Шулай да ник мәхәббәтне кылычтан өстен күреп, исемгә чыгарган иҗатчылар? Моның өчен спектакльнең азагындагы репликаларга игътибар итү сорала.

«Нәрсәгә безгә революция?!. Үз илеңдә нинди көрәш ул?!. Чәчәкле-чуклы тормыш кирәк булса, тыныч юл белән төзе син аны. Пугачев казаклары ни кыланды һәм нәрсәгә иреште?» - дип бер якта атаман тузына (Илфат Әскәров).

«Утка салсалар, утка керәм, суга салсалар, суга төшәм, гел синең янында булырмын, җаным... Нигә син ул (Петлюк) әйткәнне генә хаклы дип саныйсың? Бәлки ул сиңа өйдән-өйгә



кереп, кешеләрнең малын таларга кушар, мәчет манарасын кис, дияр. Аллаһ юк дип әйтергә кушар. Кешене кылыч белән чап, байның йортына ут төрт, тигезлибез дип, тартып алынган малны сиңа да, миңа да бирергә, ата-бабаңны каһәрләргә кушар. Алай итеп кем генә бәхетле була алыр? Бүген без бәхетсезмени? Җир йөзендә мәхәббәт барында без бәхетсезмени? Мин синең кебек ирләрчә фикер йөртмим. Гади генә хатын-кыз буларак кына уйлыйм. Дөньям тыныч, баш өстемдә түбә, учагымда ут янса, өйдә бишек тирбәлсә, син елмаеп кайтып кергәндә балаларым белән синең кочагыңа сарылсам, шул бәхет түгелмени? Нигә ялган ялтыравыкка алданып, алтын алкадай пар бәхетебезне җимерергә? Кемгәдер кирәк булса, миңа кирәкми», дип икенче якта кулга алынган Миңлебайның хатыны Мәрьям өзгәләнә.

«Кәләшең хак сүз сөйли, Миңлебай, күрәзәче диярсең. Пролетариат диктатурасы урнаштырабыз, социалистик җәмгыять төзибез дибез икән, безнең башка юлыбыз юк. Байның малын тартып алмасаң, әллә үзе йөгерә-йөгерә китереп бирер дисеңме?!. Күп халыкның мие дин белән томаланган. Мәчетләр-чиркәүләр бутый башларны. Дин йортларын, поп-муллаларны юк итми торып, аларга берни дә аңлатып булмаячак... Безнең идеябез юлында сиңа йөзләрне-меңнәрне юк итәргә туры киләчәк. Атарга, асарга, суярга, яндырырга... Мин синең кебекләрне файдаланам гына, безнең идеябез яшәсен, башкаларның миенә ныграк сеңеп калсын өчен синең кебекләр кирәк. Үтер мине! Ты должен почуветвовать вкус крови! Будь как я», - дип өченче тарафта Петлюк майга ут өсти.

Миңлебай боларның кайсына иярер? Спектакльне иҗат итүчеләр, алканы исемгә чыгарып, үз җавабын биргән бугай. Чыннан да, Миңлебай Петлюкны үтереп, яңадан патша казаклары сафына баса... Тамашачы исә кайсын сайлый - алканымы, кылычнымы? Кем ул казак - ирек сөюче, Пугачев кебек фетнәчеләргә ияргән кебек, җай чыккан саен бәйсезлек өчен көрәшүчеме, әллә, ач тамагым, тыныч колагым, дип гомер сөрүчеме? Бу сорау спектакльне XX гасыр башы вакыйгалары кысасыннан чыгарып, киңрәк уйланырга этәрә...

**Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА**



